Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Янтуган авыл җирлегенең Вольнистан авылы

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

24 август 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегенең Вольнистан авылы гражданныр җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Рсепубликасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегенең Вольнистан авылы гражданнарының 2023 елның 28 гыйнварында кабул ителгән карары нигезендә Вольнистан авылында трактор сатып алу, юлларны кышкы чорда чистарту, җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәткән өчен килешү нигезендә түләү) максатында җыелган үзара салым акчаларының кулланмаган өлешен түбәндәге эш башкаруга юнәлдерергә:

- Вольнистан авылындагы юлларны төзекләндерү.

2. Гражданныр җыены карарын Янтуган авыл җирлегенең Вольнистан авылында махсус җиһазландырылган информацион стендларда урнаштырып игълан итәргә.

3. Әлегеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив рәсми актлар регистына кертү өчен юнәлдерергә.

Җыенда рәислек итүче Р.А.Җамалтдинов

Җыен сәркәтибе Г.З.Гайнетдинова